ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.08.2020 г. Заинск № 330

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасын раслау турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль закон, Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты


**карар бирә:**

1. Зәй муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасын кушымта нигезендә расларга.
2. «Зәй муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасын раслау турында» 2014 елның 30 гыйнварындагы 189 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Зәй муниципаль районының http//zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.
4. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **М.И. Захарова**

Р.Р. Исламова
3 47 87

Приложение к постановлению
Исполнительного комитета
Заинского муниципального района



## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасы

### 1. Аңлатма язуы

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль милкендә һәм дәүләт милкендә булган, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, җир кишәрлекләрендә, шулай ук биналарда, корылмаларда яки башка күчемсез милектә реклама конструкцияләрен урнаштыру бары тик реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасы нигезендә генә рөхсәт ителә

Аларны урнаштыру шушы урыннарда рөхсәт ителә торган реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасы реклама конструкцияләрен урнаштыру урыннарын, реклама конструкцияләре типларын һәм төрләрен билгеләүче документ булып тора.

Реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасы территориаль планлаштыру документларына туры килергә һәм барлыкка килгән төзелешнең тышкы архитектур кыяфәтен, шәһәр төзелеше нормаларын һәм кагыйдәләрен, куркынычсызлык таләпләрен үтәүне тәэмин итәргә һәм реклама конструкцияләренең төрләрен һәм типларын, мәгълүмат кырларының мәйданын һәм реклама конструкцияләренең техник характеристикаларын күрсәтеп, реклама конструкцияләрен урнаштыру карталарын үз эченә алырга тиеш.

Реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасы һәм аңа кертелә торган үзгәрешләр Россия Федерациясенең тиешле субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы белән Россия Федерациясенең әлеге субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә алдан килештерелергә тиеш.

Реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасы һәм аңа кертелә торган үзгәрешләр муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

Схема: реклама конструкцияләре төрләрен билгели торган аңлатма язуыннан һәм реклама конструкцияләре исемлегеннән тора.

Схемада гамәлдәге реклама конструкцияләре һәм аларны урнаштыру урыннары күрсәтелә.

### 2. Реклама конструкцияләренең типлары һәм төрләре, реклама конструкцияләренең техник характеристикалары

Зәй муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасы белән түбәндәге төр реклама конструкцияләрен урнаштыру каралган:

1. Щитлы җайланмалар - мәгълүматны урнаштыру өчен тышкы өслеге булган һәм фундаменттан, каркастан һәм мәгълүмат кырыннан тора торган аерым конструкцияләр.

Типлаштырылган щитлы җайланмалар мәгълүмат кырының үлчәмнәре буенча түбәндәге төрләргә аерыла:

- зур форматтагы щитлы конструкцияләр (2 х 3 м, 3 х 6 м., аннан артыграк);


- кече форматтагы щитлы конструкцияләр (1,8 х 1,2 м һәм аннан кимрәк).

Щитлы җайланмалар, кагыйдә буларак, ике яклы вариантта башкарыла. Бер яклы вариантта эшләнгән щитлы җайланмаларның декоратив рәсмиләштерелгән арткы ягы булырга тиеш. Аерым торучы җайланмаларның фундаментлары җир өсте тигезлегеннән чыгып тормаска яки декоратив бизәлешле булырга тиеш. Визуаль кабул итүне боза торган беркетү һәм ныгытуның конструктив элементлары (болт лы тоташтырулар, терәү элементлары, технологик косынкалар һ.б.) декоратив элементлар белән капланырга тиеш.

Щитлы җайланмаларда конструкцияләрнең төрле өлешләрен тоташтыруның күзгә күренеп тора торган элементлары (конструкцияләрнең торц өслекләре, яктырту арматурасы, нигез белән тоташтырулар) булмаска тиеш.

Щитлы җайланмалар мәҗбүри тәртиптә куркынычсызлыкка техник экспертиза узарга тиеш.

Щитлы конструкцияләр арасындагы ераклык конкрет шәһәр төзелеше ситуациясе белән билгеләнә, ләкин кимендә 100 м булырга тиеш, ә кече форматтагы конструкцияләр өчен - кимендә 40 м .




2. Тышкы рекламаның киң таралган форматы - рекламалы тарттырылмалар (транспарант-тарттырылма). 1,0м х 7,0 м зурлыктагы ике яклы реклама полотносы.

Транспарант-тарттырылмалар үз терәкләреннән, үз терәкләренә яки биналарның фасадына беркетү җайланмаларыннан, тарттыру һәм мәгълүмати сурәт җайланмаларыннан тора. Транспарант-тарттырылмаларны яктырту терәкләренә урнаштыру рөхсәт ителә.


Транспарант-тарттырылмалар каты материаллардан һәм йомшак нигездән ясалган яктыртылган (шул исәптән гирляндалар), яктыртылмаганга бүленә.

Яктыртылган транспарант-тарттырылмалар конструкциясендә авария очрагында электр челтәрләреннән сүндерү җайланмасы булырга тиеш.

Транспарант-тарттырылма хуҗасы турында мәгълүмати табличка - терәктә яки бинаның фасадына беркетелгән урыныннан турыдан-туры якын җирдә урнашкан булырга тиеш; текст күләме аның иң кырый уң як хәрәкәт полосасыннан укуны тәэмин итәргә тиеш.

Транспарант-тарттырылмаларны юл коймаларына, күпер аша чыгу коймаларына һәм башкаларга урнаштыру рөхсәт ителми.

Контакт челтәре терәкләрендә урнаштырылган транспарантлар йомшак нигездәге тукымадан әзерләнергә тиеш.



### 3. Реклама конструкцияләренә куела торган гомуми таләпләр

Юл хәрәкәте билгеләренә, аларның терәкләренә яисә юл хәрәкәтен җайга салу өчен билгеләнгән теләсә нинди башка җайланмаларга реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү рөхсәт ителми.

Реклама конструкцияләре һәм аларның территориаль урнашуы тиеш:

- техник регламентлар таләпләренә туры килергә. Техник регламентлар булмаганда, «Автомобиль юлларында һәм шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрендә тышкы реклама. Тышкы реклама чараларына гомуми таләпләр. Урнаштыру кагыйдәләре» Р 52044-2003 ГОСТ билгеләгән таләпләргә;

- Зәй муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәдә билгеләнгән Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан төзелешнең тышкы архитектур йөзен саклауны тәэмин итә торган таләпләрне исәпкә алып билгеләнергә;

- реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтләр нигезендә урнаштырылырга һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль берәмлекләрен төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә тиешле хәлдә тотылырга;

- яктыртуга тоташкан очракта, авария хәлендә электр белән тәэмин итү системасыннан сүндерү системасы белән җиһазландырылырга һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләренә туры килергә.

Реклама конструкцияләрен проектлау, әзерләү һәм урнаштыру төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре таләпләре нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш.

Реклама конструкциясенең хуҗасының исеме, контакт өчен телефоны, аны урнаштыруга рөхсәт номеры күрсәтелгән табличка рәвешендә маркировкасы булырга тиеш.

Реклама конструкцияләрендә мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт телендә һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре турында закон таләпләрен үтәп урнаштырылырга тиеш.

## 4. Схемага үзгәрешләр кертү

Реклама конструкцияләрен урнаштыру төрен һәм урынын билгеләүче карталарның, график материалларның эчтәлеге үзгәрү “Реклама турында” Федераль законда билгеләнгән тәртиптә кирәк булганда гамәлгә ашырыла.

Шулай ук схемага түбәндәге очракларда үзгәрешләр кертү таләп ителә:

-урнаштыру рөхсәт ителгән урында яңа реклама конструкцияләре урнаштыру - реклама конструкцияләре исемлегенә үзгәрешләр кертү;



-Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре территориясе өлешендә схеманың гамәлдәге таралуыннан чыгып, схеманы карталар белән тулыландыру;

- аларның урнашуы реклама конструкциясен урнаштыру яки аны эксплуатацияләү мөмкинлегенә йогынты ясый торган төзелеш башлану, капиталь төзелеш объектларын файдалануга тапшыру - график материалларга үзгәрешләр кертү (реклама конструкциясенең башка төренә шартлы билге үзгәрү яки аны юкка чыгару);

- реклама конструкцияләре төрләренең һәм график материалларның санын, тасвирламасын үзгәртү кирәклеге (реклама конструкциясенең башка төренә шартлы билге үзгәрү яки аны алып ташлау).


Реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасы һәм аңа кертелә торган үзгәрешләр Россия Федерациясенең әлеге субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясенең тиешле субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы белән алдан килештерелергә тиеш.

Реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасы һәм аңа кертелә торган үзгәрешләр муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

| п/п №, схемада позициясе | Реклама конструкциясенең тибы | Реклама кыры мәйданы | Реклама конструкциясе урнашкан урын адресы, координаталар | Схема буенча тибы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Еврощит, 3х6м.<br>ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Җиңү пр., 26 йорт каршында, «Лукойл» АЗСы янында<br>(55.296953, 51.989715) |  |
| 2 | Еврощит, 3х6м.<br>реклама щиты (соц. реклама формасында)<br>Ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй шәһәре, Җиңү проспекты, «Каенкай» тукталышы каршында<br>(55.294968, 51.988489) |  |
| 3 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м.,<br>ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй шәһәре, Җиңү пр., (1/02 номерлы күпфатирлы торак йорт каршында)<br>(55.294427, 51.989288) |  |
| 4 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м.,<br>ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй шәһәре, Җиңү проспекты,<br>(1/04 номерлы күпфатирлы торак йорт каршында)<br>(55.293936, 51.989751) |  |
| 5 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м.,<br>ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй шәһәре, Җиңү проспекты,<br>(1/06 номерлы күпфатирлы торак йорт каршында)<br>(55.293590, 51990238) |  |
| 6 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м.,<br>ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй шәһәре, Җиңү проспекты,<br>(1/08 номерлы күпфатирлы торак йорт каршында)<br>(55.293301, 51.990738) |  |
| 7 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м.,<br>ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй шәһәре, Җиңү проспекты,<br>(1/10 номерлы күпфатирлы торак йорт каршында)<br>(55.292002,51.992612) |  |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 8 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м., ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Җиңү пр., Федераль казначылык бинасы янында, Р.Ш. Фәрдиев паркы каршында (55.289812, 51.992487) |  |
| 9 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м., ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Җиңү пр. (19 нчы торак йорт ягыннан) (55.288471, 51990055) |  |
| 10 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м., ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Нефтьчеләр пр., Кармалка елгасы аша күпердән соң 1 «а» поз. (55.287078,51.990833) |  |
| 11 | Транспарант-тарттырылма (сузылуы 1,0х7,0м.) бер яклы (соц. реклама сыман) | 7 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Ленин ур., 2 нче йорт янында (соц. Реклама сыман) (55.286378, 51.999315) |  |
| 12 | Транспарант-тарттырылма (сузылуы 1,0х7,0м.) ике яклы (соц. реклама сыман) | 14 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Энергетиклар ур., 2 нче йорт янында (соц.реклама сыман) (55.286065, 52.003655) |  |
| 13 | Транспарант-тарттырылма (сузылуы 1,0х7,0м.) ике яклы (соц. реклама сыман) | 14 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Энергетиклар ур., 13 нче йорт янында (соц.реклама сыман) (55.281722, 52.002858) |  |
| 14 | Еврощит 3х6м. реклама щиты (соц. реклама сыман) ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Нариманов ур., АЗС янында, Әлмәт шәһәренә таба "Уңыш" б/ш каршында (55.271236,52.006789) |  |
| 15 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м., ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Нариманов урамы чатында, шәһәрдән Әлмәт шәһәренә таба чыкканда («Оренбург газ»га борылыр алдыннан) (55.275830, 52007753) |  |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 16 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м., ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Нариманов ур. (Никифоров урамы чатыннан 50 м.да) (55.277880, 52007847) |  |
| 17 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м., ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Нариманов ур. (Комсомол урамы чатында) (55.279708, 52008056) |  |
| 18 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м., ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Нариманов ур. («Энергетик» г/җ керер алдыннан) (55.292808, 52.008170) |  |
| 19 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м., ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Нариманов ур., «Энергетик» г/җ каршында (55.292206, 52.008452) |  |
| 20 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м., ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Сәнәгать ур., 1 (55.296103, 52.009562) |  |
| 21 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м., ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Нариманов ур., (Нижняя урамы чатында) (55.298240,52.005960) |  |
| 22 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м., ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Нариманов ур., (Автозавод урамы белән «Радуга» б/ш чатында) (55.299041, 52.005691) |  |
| 23 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м., ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Нариманов ур., (23 нче торак йорт каршында) (55.298198, 52.006471) |  |
| 24 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м., ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Г.Тавлин һәм Нариманов урамнары чатыннан 50 метрда (55.299725, 52005388) |  |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 25 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м., ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Нариманов ур., светофордан соң, «Зәй шикәре» ААЖ р-ны (55.301278, 52004966) |  |
| 26 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м., ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Нариманов ур., (кондитер фабрикасы каршында) (55.299790, 52.005979) |  |
| 27 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м., ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Нариманов ур., (кондитер фабрикасы ягында) (55.301255, 52005000) |  |
| 28 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м., ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Нариманов ур., (кондитер фабрикасы ягыннан) ( 55.300711, 52.005195) |  |
| 29 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м., ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Нариманов ур., «Зәй шикәре» ААҖ территориясенә борылыш каршында (55.302199, 52005195) |  |
| 30 | Еврощит - реклама щиты, 3х6м., ике яклы (соц. реклама сыман) | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Нариманов, Завод, 1 Май урамнары чатында. (55.303066, 52005034) |  |
| 31 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м., ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш., Автоюл ур. («Шашлычная» кафесы каршында) (55.305731, 52.021672) |  |
| 32 | Еврощит -реклама щиты, 3х6м., ике яклы | 36 кв.м. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй ш. Яр Чаллы юлы - Әлмәт юлы - «ДРСУ» юлы кисешкән чаттан 100 метрда (55.319161, 52.026749) |  |